СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.05.2023 г.Зеленодольск № 280

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек аларга карата вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән, шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге 473 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән үз ихтыяҗлары өчен шөгыльләнүе һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2018 елның 22 декабрендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен кабул итү белән, Зеленодольск муниципаль район Советы **карар кылды**:

2011 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек аларга карата вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән, шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен раслау турында» 125 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарындагы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге 473 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (кушымта бирелә).

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы ,Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск Советының
2011 елның 30 декабрендәге
125 номерлы карарына кушымта
(2023 елның 30 маендагы
280 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек аларга карата вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән, шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен,
Зеленодольск муниципаль районында:

(кв. м)

| | «Зеле-нодольск шәһәре» МБ | «Васильево штп »МБ | «Карамалы Тау штп» МБ | «Осиново авыл җирлеге» МБ | башка авыл җирлекләре |
|---|---|---|---|---|---|
| Индивидуаль торак төзелеше | 600 | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 |
| Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару | - | - | - | 1000 | 1000 |
| Бакчачылык | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 |
| Яшелчәчелек | 600 | 600 | 1000 | 600 | 1000 |